КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 8 июль г.Казань № 566

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, модернизацияләү, эксплуатацияләү чараларын координацияләү тәртибе турында» 2015 ел, 30 май, 387 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, модернизацияләү, эксплуатацияләү чараларын координацияләү тәртибе турында» 2015 ел, 30 май, 387 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 12 октябрь, 740 нчы; 2018 ел, 12 сентябрь, 772 нче; 2019 ел, 18 март, 189 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә файдаланыла торган Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларын булдыру, модернизацияләү һәм (яки) сатып алу чараларын планлаштыру һәм тормышка ашыру, проект заявкасына экспертлар бәяләвен үткәрү тәртибен.»;

2 нче пунктта «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгын» сүзләренә алыштырырга;

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына мәгълүматлаштыру чараларын тормышка ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, модернизацияләү, эксплуатацияләү чараларын координацияләү турындагы нигезләмәгә һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә файдаланыла торган Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларын булдыру, модернизацияләү һәм (яки) сатып алу чараларын планлаштыру һәм тормышка ашыру, проект заявкасына экспертлар бәяләвен үткәрү тәртибенә таянып эш итәргә.»;

4 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына:»;

7 нче пунктта «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, модернизацияләү, эксплуатацияләү чараларын координацияләү турындагы нигезләмәдә:

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Нигезләмә «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау хакында» 2006 ел, 27 июль, ФЗ-149 нчы Федераль закон, «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 ел, 13 ноябрь, ТРЗ-58 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларын планлаштыруны, булдыруны һәм кулланылышка кертүне гамәлгә ашыру һәм координацияләү тәртибен билгели.

Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы дәүләт һәм тармак программалары кысаларында да, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары кысаларында да Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан эксплуатацияләү барышында булдырыла, сатып алына, эксплуатацияләүгә кертелә, модернизацияләнә торган Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларына кагыла.»;

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган терминнар:

Татарстан Республикасы мәгълүмат системасы – Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнарының хокукый актлары нигезендә, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт органнары тарафыннан үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру процессында булдырылган мәгълүмат системасы;

мәгълүматлаштыру буенча вәкаләтле орган – дәүләт органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, модернизацияләү, эксплуатацияләү чараларын координацияләү өчен, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә товарларны (эшләрне, хезмәтләрне) булдыру, алардан файдалану һәм аларны сатып алу буенча чараларны планлаштыру кысаларында кулланыла торган документларга экспертлар бәяләвен үткәрү өчен җаваплы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы;

Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру программасы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән билгеләнгән тәртиптә раслана торган һәм дәүләт функцияләрен тормышка ашыру кысаларында мәгълүматлаштыру өлкәсендә өстенлекләргә һәм максатларга ирешүне тәэмин итүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының чаралар системасын һәм сәясәт инструментларын үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программасы;

Татарстан Республикасының мәгълүмат системасы операторы(-лары) – мәгълүмат системасын эксплуатацияләү буенча, шул исәптән мәгълүматлар базасында булган мәгълүматны эшкәртү буенча эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы дәүләт органы(-нары), аның (алар) тарафыннан вәкаләтләр бирелгән бюджет учреждениеләре;

мәгълүматны эшкәртү – мәгълүмат белән эшләү (мәгълүмат җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, яңартуны, үзгәртүне, куллануны, таратуны (шул исәптән тапшыруны), блокировкалауны һәм юк итүне кертеп);

Татарстан Республикасы мәгълүмат системасының функциональ заказчысы – Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларын булдыруга, модернизацияләүгә һәм (яки) сатып алуга ихтыяҗны билгели торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары.

Концессион килешү яки дәүләт-хосусый партнерлык турындагы килешү нигезендә Татарстан Республикасы мәгълүмат системасын булдырган яки модернизацияләгән очракта, әлеге система операторы функцияләре концессионер яки хосусый партнер тарафыннан тиешле килешүдә каралган чикләрдә, күләмнәрдә һәм вакытларда гамәлгә ашырыла.»;

3 нче пунктта:

беренче абзацта «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

2 нче бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен планлаштыру һәм булдыру тәртибе»;

түбәндәге эчтәлекле $5^1$ нче пункт өстәргә:

«$5^1$. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары Мәгълүматлаштыру буенча вәкаләтле органга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә файдаланыла торган Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларын булдыру, модернизацияләү һәм (яки) сатып алу чараларын планлаштыру һәм тормышка ашыру, проект заявкасына экспертлар

бәяләвен үткәрү тәртибенә теркәлгән кушымта нигезендә Татарстан Республикасы мәгълүмат системасын эшләү, сатып алу һәм модернизацияләү турында проект заявкасын җибәрә.»;

6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Татарстан Республикасы мәгълүмат системасын булдыруда, модернизацияләүгә һәм сатып алуга ихтыяҗ барлыкка килгән очракта, Татарстан Республикасы мәгълүмат системасының функциональ заказчысы мәгълүматлаштыру буенча вәкаләтле органга түбәндәге мәгълүматны җибәрә:

Татарстан Республикасы мәгълүмат системасын модернизацияләүгә проект заявкасын, әгәр дә мондый мәгълүмат системасы эксплуатациягә кертелгән булса (мәгълүмат системасын модернизацияләүгә ихтыяҗ турындагы мәгълүмат функциональ заказчыга берничә файдаланучыдан кергән очракта, ул модернизацияләү инициаторы булып тора);

әгәр Татарстан Республикасы мәгълүмат системасы булдырылырга планлаштырылса, аны булдыруга проект заявкасын;

әгәр Татарстан Республикасы мәгълүмат системасын сатып алырга планлаштырылса, аны сатып алуга проект заявкасын.»;

7 нче пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

9 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Татарстан Республикасы мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәдә Татарстан Республикасы мәгълүмат системасының исеме, аны булдыру максаты һәм аның функциональ мөмкинлекләре тасвирламасы күрсәтелә, Татарстан Республикасы мәгълүмат системасының заказчысы һәм операторы билгеләнә.»;

10 – 18 нче пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

19 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Мәгълүматлаштыру буенча чараларны үтәү мониторингы, функциональ заказчылар белән берлектә, мәгълүматлаштыру буенча вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

әлеге карарга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә файдаланыла торган Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларын булдыру, модернизацияләү һәм (яки) сатып алу чараларын планлаштыру һәм тормышка ашыру, проект заявкасына экспертлар бәяләвен үткәрү тәртибен (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин